ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 28 Бәйрәкәтамак ав. 17 декабрь 2018 ел

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак
авыл җирлеге Советының 2018 елның
21 маендагы 10 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 санлы карары нигезендә, (24.04.2018 ел, №281 редакциясендә) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 10 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 1 бүлегендәге 3 пунктта «унбер айлык акчалата бүләк» сүзләрен «4,65 айлык акчалата бүләк» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында да Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча элəргә: www.yutaza.tatar.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы: З.М.Әһлиева